РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ» ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 11 декабре** **Чистай шәһәре** **№42/5**

2020 елга Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Чистай шәһәре» муниципаль
берәмлеге милкендәге мөлкәтне
хосусыйлаштыру буенча фараз планы
(программасы) хакында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 21.12.2001 елның 21 декабрендәге, 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставыны нигезләнеп, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыру буенча фараз планын (программасын) кушымта нигезендә расларга.
2. 2020 елга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru), шулай ук торглар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясенең рәсми сайтында (torgi.gov.ru) урнаштырырга.
3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр Советының бюджет һәм фаразлау, сәнәгать һәм эшкуарлык буенча даими депутат комиссиясенә (Миңнегалеев Н.В.) йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр башлыгы Д.А. Иванов

Чистай шәһәр Советының
2019 елның 11 декабрендәге 42/5
номерлы карарына кушымта

**2020 елга Татарстан Республикасы**
**Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыру буенча фараз планы (программасы)**

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1.«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, 2020 елга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) эшләнде.

1.2. 2020 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру муниципаль милеккә идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль мөлкәтне сатудан бюджет кытлыгын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

1.3. «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны аукционда, яисә конкурста сату юлы белән һәм законда каралган башка ысуллар белән башкару күздә тотыла.

## 2 бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

2.1. 2020 елда муниципаль казнадагы һәм шәһәр бюджетыннан финансланучы оешмалардан файдаланылмый торган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырырга тиеш.

2.2. Хосусыйлаштыруга планлаштырылган муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге:

| № т/н | Объект исеме | Урнашкан адресы | мәйданы кв. м. | | Хосусыйлаштыруның күздә тотыла торган срогы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Объект | җир кишәрлеге | |
| 1 | Торак булмаган бина, клуб | Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре М.Поликарпова ур., 9б й. | 170 | 289 | 1-2 кв. |
| 2 | Торак булмаган бина | Татарстан Республикасы, Чистай ш., К.Маркс ур., 23 йорт (Н-2 бүлмә) | 98,2 | | 1-2 кв. |
| 3 | Торак булмаган бина, психологик-педагогик үзәк | Татарстан Республикасы, Чистай ш., Галактионов ур., 42 й. | 306,2 | 1 779 | 1-2 кв. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Торак булмаган бина, административ | Татарстан Республикасы, Чистай ш., Мир ур., 48 й. | 771,4 | | 2-3 кв. |
| 5 | Торак булмаган бина | Татарстан Республикасы, Чистай ш., Ленин ур., 68 й. | 1 380,7 | 5 995 | 2-3 кв. |
| 6 | Торак булмаган бина | Татарстан Республикасы, Чистай ш., Ленин ур., 68 й. | 73,8 | | 3-4 кв. |
| 7 | Торак булмаган бина | Татарстан Республикасы, Чистай ш., Ленин ур., 68 й. | 166,9 | | 3-4 кв. |
| 8 | Торак булмаган бина | Татарстан Республикасы, Чистай ш., Ленин ур., 68 й. | 268,4 | | 3-4 кв. |
| 9 | Торак булмаган бина | Татарстан Республикасы, Чистай ш., Ленин ур., 68 й. | 105,9 | | 3-4 кв. |

2.3. 2020 елда муниципаль милектәге муниципаль унитар предприятиеләрне һәм акцияләрне хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

2.4. Муниципаль мөлкәтне, шул исәптән мондый мөлкәтне сатып алучы заттан, мондый мөлкәт биләгән һәм алардан файдалану өчен кирәкле җир кишәрлекләрен читләштерү белән бер үк вакытта сатыла торган мөлкәтне хосусыйлаштыру турындагы карар Чистай шәһәр Советы карарлары нигезендә Чистай шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

**3 бүлек. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү**

3.1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру һәм колачлырак реклама белән тәэмин итү турында оператив мәгълүмат бирү максатыннан, Чистай шәһәр башкарма комитеты әлеге фараз планын үтәү барышында мәгълүматның рәсми чыганакларыннан тыш, башка массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтләреннән файдаланырга хокуклы.